Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXV-5**

2023 елның 6 апреле

Балык Бистәсе штп.

Техник регламентларның объектларның ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка сыйфатламалары таләпләренә, Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан әлеге объектларның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 17 июнендәге L-2 карары белән расланган проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның техник торышын бәяләү һәм тиешле техник хезмәт күрсәтү максатларында биналарны, корылмаларны Карау уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм "Конкуренцияне яклау турында"гы Федераль законның 18.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 19 декабрендәге 541-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Техник регламентларның объектларның ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка сыйфатламалары таләпләренә, Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан әлеге объектларның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 17 июнендәге L-2 карары белән расланган проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның техник торышын бәяләү һәм тиешле техник хезмәт күрсәтү максатларында биналарны, корылмаларны Карау уздыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4. пунктының 2 абзацына "һәм башкарма документлар нигезендә;" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов